РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
УЛИЦА ЛЕНИНА,
ДОМ 76 «а»
СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ, 423106

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а
БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ, 423106

тел./факс email: +7(84396) 2-64-66;
Berk.Cmn@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14 октябрь 2025 ел № 2

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
«Бәркәтә авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең
генераль планы проекты буенча
гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Бәркәтә авыл җирлеге Уставының 17 статьясы, Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 6 маендагы 14 номерлы карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар уздыру юлы белән проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (1нче кушымта).

2.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү комиссиясе
(2 нче кушымта)

- үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 28 октябрендә 10.00 сәгатьтә.

- үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Бәркәтә авыл җирлеге, Бәркәтә авылы, Ленин ур., 76а йорт адресы буенча урнашкан Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы.

3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2025 елның 27 октябренә кадәр эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, түбәндәге адрес буенча кабул ителә:
Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Бәркәтә авыл җирлеге, Бәркәтә авылы, Ленин ур., 76а йорты буенча язма рәвештә.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын танышу өчен мәгълүмат стендларында урнаштырырга;

- гамәлдәге законнар нигезендә проект турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгарырга;

Бәркәтә авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә кертергә;

- әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Бәркәтә авыл җирлеге
башлыгы Р.М. Сибгатуллин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2025 елның 14 октябрендәге
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Бәркәтә авыл җирлегенең генераль планы проектын**
**тикшерү буенча комиссия составы**

Сибгатуллин Ринат Мәхмүт улы - Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы;

Мусина Миләүшә Фәтхи кызы - Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Эшче төркем әгъзалары:

Вилданов Муса Габделхак улы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча);

Җиһаншина Эльвира Борындай кызы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Гераева Наталья Михайловна - «Чирмешән муниципаль районында җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча);

Рунова Татьяна Викторовна - Чирмешән муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы, Чирмешән муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);

Гинванов Габдрәшит Габдрахман улы - 3 нче сайлау участогы Бәркәтә авыл җирлеге депутаты (килешү буенча).